РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН НАРАТБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 елның 22 мае 6 нчы номерлы

Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2013 елның 07 ноябренең 18 номерлы
карары белән расланган «Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге
территориясендә муниципаль торак контролен
гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезләмә»гә
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Торак кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон, 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законы, Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезләмә»гә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 3.3 пунктының 1 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә расларга: «Дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау турындагы уведомлениегә туры китереп, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлады;».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Буа муниципаль районы
Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгының
вазифаларын башкаручы И.И. Гәлиуллин